# Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге советының IV чакырылыш X утырышы

**К А Р А Р № 20**

Татар Бүләр авылы «14» май 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Исәнсеф авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампалар җыюны оештыру турында» 2014 елның 28 мартындагы 1 номерлы Исәнсеф авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгару хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын уздырганда бәяләнә торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын юкка чыгару турында» 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Исәнсеф авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампалар җыюны оештыру турында» 2014 елның 28 мартындагы 1 номерлы Исәнсеф авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгарырга.
2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Исәнсеф авыл җирлеге башлыгы** **И.А.Салихов**